МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.03.2016 Казан шәһәре № 91

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү Тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм башка мактау билгеләрен кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 10 октябрендәге 506 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә һәм азат ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм башка мактау билгеләрен кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 12 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул

итүнең кушып бирелә торган Тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Кадрлар бүлеге башлыгына (Садыйкова В. Р.) тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм гражданнарны алар белән хезмәт контрактлары төзегәндә әлеге боерык белән таныштыру;

3. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек бүлегенә (Сәгыйтов И.С.) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталының Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Министр вазыйфаларын башкаручы –**
**Эшкуарлыкны үстерү департаменты**
**директоры** **Р.Р. Сибгатуллин**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 31 мартындагы 91 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәре, Министрлык) тарафыннан, әгәр граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларына күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек керә икән, чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәннидән тыш) (алга таба – исемнәр, бүләкләр) кабул итү процедурасын регламентлый.

2. Граждан хезмәткәре исем, бүләкләр алганда Татарстан Республикасы икътисад министры (алга таба – министр) рөхсәтен алырга тиеш.

3. Исем, бүләкләү алган, яисә чит дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмә тарафыннан аларны алачаклыгы турында хәбәр ителгән граждан хезмәткәре өч эш көне дәвамында чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус исемен, бүләкләвен кабул итүгә рөхсәт бирү турында кадрлар бүлегенә әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән гариза (алга таба – гариза) тапшыра.

Гаризаны карау вакыты, кадрлар бүлеге тарафыннан әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә гаризаны теркәгән көннән соң, ун эш көне тәшкил итә.

4. Исемнән, бүләктән баш тарткан граждан хезмәткәре өч эш көне дәвамында чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус исемен, бүләген алудан баш тарту турында кадрлар бүлегенә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) тапшыра.

5. Министр тарафыннан гаризаны карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгәнчегә кадәр исем, бүләк алган граждан хезмәткәре исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен аларны алган көннән алып өч эш көне эчендә Министрлыкның эшләр идарәчесенә җаваплы саклауга тапшыра. Шул ук вакытта әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә форма буенча кабул итү-тапшыру акты төзелә.

6. Хезмәт командировкасы вакытында граждан хезмәткәре исем, бүләк алган яки алардан баш тарткан очракта, гариза яисә хәбәрнамә бирү вакыты граждан хезмәткәренең хезмәт командировкасыннан кайткан көненнән исәпләнә.

7. Граждан хезмәткәре аңа бәйле булмаган сәбәп буенча гариза яки хәбәрнамәне, исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен әлеге Тәртипнең 3-5 пунктларында күрсәтелгән вакытта тапшыра алмаса, ул гариза яки хәбәрнамәне, исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен бу сәбәпне бетергәннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

8. Гаризаны (хәбәрнамәне) әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә төзелгән формада теркәү журналында теркәү кадрлар бүлеге тарафыннан кергән көнне башкарыла. Теркәлгән гариза (хәбәрнамә) ике эш көне дәвамында Министрга карап тикшерү өчен җибәрелә.

9. Кадрлар бүлеге ике эш көне дәвамында граждан хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре буенча министр тарафыннан кабул ителгән карар турында хәбәр итә һәм аңа гаризаның (хәбәрнамәнең) билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсен министр резолюциясе белән бергә кул куйдырып тапшыра. Министр резолюциясе белән гаризаның (хәбәрнамәнең) төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшенә кушыла.

10. Министр тарафыннан граждан хезмәткәренең әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән гаризасы канәгатьләндерелгән очракта, Министрлык эшләре белән идарә итүче 10 эш көне дәвамында граждан хезмәткәренә исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм ааларга документларның төп нөсхәләрен тапшыра. Шул ук вакытта әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә форма буенча кабул итү-тапшыру акты төзелә.

11. Министр әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән граждан хезмәткәренең гаризасын канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, кадрлар бүлеге 10 эш көне дәвамында исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен чит дәүләтнең тиешле органына, халыкара оешмага, сәяси партиягә, башка иҗтимагый берләшмәгә, дини берләшмәгә җибәрә.

_______________________

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы икътисад министрына

________________________________________
(ФИА)

кемнән ________________________________
(вазыйфаның атамасы)

________________________________________

________________________________________

________________________________________
(ФИА, телефон номеры)

# Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус исемен, бүләген кабул итүгә рөхсәт бирү турында гариза

Рөхсәт итегез миңа ________________________________________________ кабул итәргә
(мактаулы яисә махсус исем, бүләкләр атамасы)

________________________________________________________________________
(нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелде, нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнә)

________________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемгә, бүләкләүгә документлар тапшыру датасы һәм урыны)

Мактаулы яисә махсус исемгә документлар, бүләк һәм аңа документлар (кирәклесенең астына сызарга) ____________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исем, бүләкләр атамасы)

________________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемгә, бүләкләүгә документларның исеме)
_______________________________________________ 20___ елның ___ «__________» ___ номерлы кабул итү-тапшыру акты буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының эшләр идарәчесенә тапшырылды.

«__ » 20 _______________ ел

________________________________________________________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы **икътисад** министрына

___________________________________

(ФИА)

кемнән____________________________

(вазыйфаның атамасы)

_________________________.___________________

___________________________________________.

(ФИА, телефон номеры)

## Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус исемен, бүләген алудан баш тарту турында хәбәрнамә

Мин _______________________________________________________________

(мактаулы яисә махсус исем, бүләкләр атамасы)

_______________________________________________________________

(нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелде, нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнде)

алудан баш тарту турында кабул ителгән карар турында хәбәр итәм

«__» __________ 20___ ел

_____________________ ____________________________

(имза) (имзаның расшифровкасы

()

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре
тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара
оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый
берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы
һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибенә
3 нче кушымта

Кабул итү-тапшыру
акты

« __ » _____________20___ ел №  ___

Без, түбәндә кул куючылар, ___________________________________________
(ФИА, вазыйфасы)
тапшырды/кабул итте (кирәклесенең астына сызарга), әТатарстан Республикасы Икътисад министрлыгының эшләр идарәчесе ________________ (ФИА) түбәндәгеләрне кабул итте/тапшырды (кирәклесенең астына сызарга) турында акт төзедек:

| т/б № | Исеме | Саны (данә) | Исемлек |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тапшырды
______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Кабул итте
_______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибенә 4 нче кушымта

# Гаризаларны (хәбәрнамәләрне) исәпкә алу ЖУРНАЛЫ

| № | Гариза (хәбәрнамә) тапшырган граждан хезмәткәренең ФИА | Гариза (хәбәрнамә) тапшырган граждан хезмәткәренең вазыйфасы | Гариза (хәбәрнамә) керү датасы | Бүләкнең, исемнең атамасы | Кабул итү-тапшыру актының реквизитлары (булганда) | Гариза (хәбәрнамә) кабул иткән затның имзасы, ФИА | Гариза (хәбәрнамә) биргән затның имзасы, ФИА | Министр карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |